РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

---

*Решение* *Карар*

2021 елның 20 октябре Чистай шәһәре № 10/1

«2021 елга һәм 2022-2023 елларның
планлы чорына Татарстан Республикасының
«Чистай муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге бюджетына
үзгәрешләр кертү турында»

«2021 елга һәм 2022-2023 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына үзгәрешләр кертү турында» Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе Карманова Наталья Анфиногентовнаның докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Чистай муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Чистай муниципаль районы Советының 2020 елның 15 декабрендәге 3/2 номерлы «Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 елларның планлы чорына бюджеты турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. 2021 елга Татарстан Республикасы» «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:
1) Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 1682354,3 мең сум күләмендә;
2) Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1792780,0 мең сум күләмендә;
3) Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгының иң чик күләме 110425,7 мең сум күләмендә.».

1.2. «2021 елга Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 нче кушымтасын әлеге Карарга 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

1.3. «2021 елга Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетының фаразланучы керемнәре күләме» 3 нче

кушымтасын әлеге Карарга 2 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

1.4. «2021 елга һәм 2022-2023 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең керемнәре һәм кире кайтарылмый торган керемнәре баш администраторлары исемлеге» 5 нче кушымтасын әлеге Карарга 3 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

1.5. «2021 елга Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 7 нче кушымтасын барлык күчешләрне исәпкә алып, әлеге Карарга 4 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

1.6. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2021 елга чыгымнар классификациясе төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), төркемнәре буенча бүлү» 9 нчы кушымтасын барлык күчешләрне исәпкә алып, әлеге Карарга 5 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

1.7. 9 статьяда:
1.7.1. 1 пунктның 1, 2 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны исәпкә алырга:
- 2021 елда 1122896,2 мең сум күләмендә әлеге Карарга 18 нче кушымта нигезендә»

1.8. «2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына күчерелә торган бюджетара трансфертлар» әлеге Карарга 6 нчы кушымта нигезендә бәян итәргә.

1.9. Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарына 90619,1 мең сум күләмендә кире кайтарылмый торган кертемнәр хисабына үзгәрешләр кертергә, шул исәптән:
арттырырга:
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» 802 ведомствосы буенча 50230,6 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы» 803 ведомствосы буенча 947,4 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты» 811 ведомствосы буенча 7013,9 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» 817 ведомствосы буенча 22528,5 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» 819 ведомствосы буенча 7322,4 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге» 821 ведомствосы буенча 2576,3 мең сум күләмендә.

1.10. 9.1 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2021 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын 110185,2 мең сум күләмендә арттырырга, шул исәптән:
«Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» 802 ведомствосы буенча 10292,2 мең сум, шул исәптән 6742,6 мең сум күләмендә әлеге Карарга 23 нче кушымта нигезендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» 803 ведомствосы буенча 2375,3 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы» 810 ведомствосы буенча 2209,4 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты» 811 ведомствосы буенча 52795,6 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» 812 ведомствосы буенча 224,8 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» 817 ведомствосы буенча 29804,8 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» 819 ведомствосы буенча 9769,0 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге» 821 ведомствосы буенча 2714,1 мең сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын муниципаль районнар бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән кергән керемнәр исәбеннән 1129,6 мең сум күләмендә арттырырга, шул исәптән:
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» 803 ведомствосы буенча 666,1 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» 819 ведомствосы буенча 463,5 мең сум күләмендә.

3. Бюджетара трансфертларны кире кайтару хисабына Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын 240,5 мең сум күләмендә арттырырга, шул исәптән:
«Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» 802 ведомствосы буенча 240,5 мең сум күләмендә.

4. Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын муниципаль оешмалардан муниципаль район бюджетына кире кайтарылмый торган башка акчалар хисабына 1584,2 мең сум күләмендә арттырырга, шул исәптән:
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» 819 ведомствосы буенча 1584,2 мең сум күләмендә.

5. «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын узган елларда калган субсидияләрне бюджет учреждениеләре тарафыннан кире кайтару хисабына 100,5 мең сум күләмендә арттырырга, шул исәптән:
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» 819 ведомствосы буенча 100,5 мең сум күләмендә.

6. Чистай муниципаль районы бюджеты чыгымнарын «Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» 802 ведомствосы буенча «Резерв фондлар» 0111 бүлекчәсе буенча 1954,8 мең сум күләмендә киметергә.

7. Чистай муниципаль районы бюджеты чыгымнарын 1954,8 мең сум күләмендә арттырырга, шул исәптән:
«Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» 802 ведомствосы буенча 1039,2 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар күчерүгә 1039,2 мең сум күләмендә, әлеге Карарга 24 нче кушымта нигезендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты» 811 ведомствосы буенча 910,6 мең сум күләмендә.

8. «2021 елда 802 Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы ведомство буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирүгә чыгымнарны бүлү» 23 нче кушымтасын әлеге Карарга 7 нче кушымта нигезендә өстәргә.

9. «2021 елда Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы 802 ведомствосы буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирүгә чыгымнарны бүлү» 24 нче кушымтасын әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә өстәргә.

10. Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарына 25 нче кушымта нигезендә 15,9 мең сум күләмендә үзгәрешләр кертергә.

11. «2021 елда Чистай муниципаль районының 802 Финанс-бюджет палатасы ведомство буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирүгә чыгымнарны бүлү» 25 нче кушымтасын әлеге Карарга 9 нчы кушымта нигезендә өстәргә.

12. Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарына әлеге Карарның 26 нчы кушымтасы нигезендә 17,3 мең сум күләмендә үзгәрешләр кертергә.

13. «2021 елда Чистай муниципаль районының 802 Финанс-бюджет палатасы ведомство буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирүгә чыгымнарны бүлү» 26 нчы кушымтасын әлеге Карарга 10 нчы кушымта нигезендә өстәргә.»

2. Әлеге карарны «Чистопольские известия» һәм «Чистай хәбәрләре» газеталарында яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының бюджет һәм фаразлау буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов